КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 май г.Казань № 434

Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 139.1 статьясы, «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы, «2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы указлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Премьер-министр
Татарстан Республикасы А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 май, 434 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – муниципаль берәмлекләр, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы, «2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы указлары белән билгеләнгән бюджет өлкәсенең аерым категорияләрдәге хезмәткәрләренең эш хакы дәрәҗәсен тәэмин итүгә бәйле булган муниципаль берәмлекләр чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелә.

3. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары түбәндәгеләр була:

а) муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү хисабына муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булу;

б) Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы (алга таба – вәкаләтле орган) арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү.

6. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның гомуми күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = \sum_{j=1}^{n} (Z_j^p - Z_j^f) \times C_j \times m \times (1 + k),$$

монда:

$Z_j^p$ – план чоры өчен j-категориядәге хезмәткәрләрнең планлаштырыла торган уртача эш хакы күләме;

$Z_j^f$ – хисап чоры өчен j-категориядәге хезмәткәрләрнең факттагы уртача эш хакы күләме;

$C_j$ – барлык муниципаль берәмлекләрдә j-категориядәге хезмәткәрләрнең гомуми саны;

m – айлар саны;

k – хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр ставкасы;

n – хезмәткәрләр категорияләре саны.

7. I-муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме ($S_i$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \frac{S}{\sum_{i=1}^{t}\sum_{j=1}^{n} C_{ij}} \times \sum_{j=1}^{n} C_{ij},$$

монда:

$C_{ij}$ – i-муниципаль берәмлектә j-категориядәге хезмәткәрләр саны;

i – башка бюджетара трансфертларны алучы булган муниципаль берәмлек;

t – муниципаль берәмлекләр – башка бюджетара трансфертларны алучылар саны.

8. Башка бюджетара трансфертларны бирү Министрлык һәм вәкаләтле орган арасында Министрлык тарафыннан раслана торган форма нигезендә төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла.

9. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертның күләме, аның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең мәгънәләре;

башка бюджетара трансфертны күчерү тәртибе һәм вакытлары;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансферт торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары турында хисап һәм башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап бирү вакытлары, тәртибе һәм формалары;

вәкаләтле орган тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

бу Тәртип белән билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне өзү тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

10. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече булып хисап чоры өчен муниципаль берәмлектә бюджет өлкәсе учреждениеләренең

аерым категорияләрдәге хезмәткәрләренең Федераль дәүләт статистикасы хезмәте мәгълүматлары буенча ирешелә торган уртача хезмәт хакы дәрәҗәсе тора.

12. Министрлык килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә башка бюджетара трансфертны муниципаль берәмлек бюджеты акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә Федераль казначылыкның территориаль органына ачылган шәхси счетка күчерә.

13. Вәкаләтле орган ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 8еннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка килешүдә каралган форма һәм тәртип нигезендә финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансферт торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары турында хисап һәм башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап кертә.

14. Әгәр дә муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансферт бирү елының 31 декабре хәленә карата башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең килешү белән күздә тотылган мәгънәсенә ирешелмәгән булса, башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{\text{кире кайтару}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{\text{кире кайтару}} = P \times D \times 0{,}1\ ,$$

монда:

P – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләме;

D – башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты.

15. Муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләмен исәпләп чыгарганда хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләмендә башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата башка бюджетара трансфертның файдаланылмый калган өлеше күләме исәпкә алынмый.

16. Башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты (D) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$D = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – ел ахырына башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең килешү белән билгеләнгән план буенча мәгънәсе.

17. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансферт максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына акча кире

кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнары белән каралган мәҗбүри түләттерү чаралары кулланыла.

18. Хисап елыннан соң килә торган агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Министрлык тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә әлеге башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдәге акча агымдагы финанс елында әлеге башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры килә торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен алар элегрәк бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

19. Вәкаләтле орган бирелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертның максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

20. Министрлык бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

21. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.